ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2015, № 4; 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены белән шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре (алга таба – муниципаль берәмлекләр), оешмалар һәм аларның бүлекчәләре (алга таба – оешмалар) бүләкләнергә мөмкин, моңа дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары керми.»;

2) 8 статьяның 6 өлешендә «ордены белән» сүзләреннән соң «муниципаль берәмлекләр,» сүзләрен өстәргә;

3) 16 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $5^1$ өлеш өстәргә:

«$5^1$. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән муниципаль берәмлекләрне бүләкләү турындагы үтенечнамәләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кузгатыла.»;

б) 6 өлештә «Оешмаларны» сүзеннән соң «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән» сүзләрен өстәргә;

4) 17 статьяның 3 өлешендәге 1 пунктында «гражданның һәм оешманың» сүзләрен «гражданның, муниципаль берәмлекнең яисә оешманың» сүзләренә

алмаштырырга, «гражданнарга яисә оешмаларга» сүзләрен «гражданнарга, муниципаль берәмлекләргә яисә оешмаларга» сүзләренә алмаштырырга;

5) 19 статьяның 3 өлешендә «җирле үзидарә органнары» сүзләреннән соң «, шулай ук муниципаль берәмлекләр» сүзләрен өстәргә;

6) 21 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль берәмлек үзгәртеп корылганда яисә бетерелгәндә, оешма үзгәртеп корылганда яисә бетерелгәндә.»;

7) 25 статьяның $2^1$ өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$2^1$. Бүләкләнгән муниципаль берәмлеккә Татарстан Республикасы дәүләт бүләге, кагыйдә буларак, бүләкләнгән муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы утырышында муниципаль берәмлек башлыгына яисә ул вәкаләт биргән затка тапшырыла.

Бүләкләнгән оешмага Татарстан Республикасы дәүләт бүләге, кагыйдә буларак, бүләкләнгән оешма коллективы катнашында оешманың җитәкчесенә яисә ул вәкаләт биргән затка тапшырыла.»;

8) 26 статьяның 3 өлешендә «үзгәрүгә яисә» сүзләреннән соң «бүләкләнгән муниципаль берәмлекнең,» сүзләрен өстәргә;

9) 28 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренә лаек булган муниципаль берәмлекләрнең башлыклары Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен кую урыннарын билгелиләр, бу урыннар дәүләт бүләкләренең сакланышын һәм муниципаль берәмлек халкының алар белән таныша алу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренә лаек булган оешмаларның җитәкчеләре Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен кую урыннарын билгелиләр, бу урыннар дәүләт бүләкләренең сакланышын һәм оешма хезмәткәрләренең алар белән таныша алу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.»;

10) $31^1$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$31^1$ статья. **Бүләкләнгән муниципаль берәмлек үзгәртеп корылган яисә бетерелгән очракта, бүләкләнгән оешма үзгәртеп корылган яисә бетерелгән очракта Татарстан Республикасы дәүләт бүләген тапшырып калдыру тәртибе**

1. Бүләкләнгән муниципаль берәмлек җирле үзидарә турындагы законнар нигезендә үзгәртеп корылган очракта, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе карары белән Татарстан Республикасы дәүләт бүләге үзгәртеп корылган (яңадан төзелгән) муниципаль берәмлектә кала.

Бүләкләнгән оешма үзгәртеп корылган очракта, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе карары белән Татарстан Республикасы дәүләт бүләге әлеге оешманың хокукый дәвамчысына кала.

2. Бүләкләнгән муниципаль берәмлек бетерелгән, бүләкләнгән оешма бетерелгән очракта, Татарстан Республикасы дәүләт бүләге Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясенә кире кайтарылырга тиеш һәм саклау һәм экспонат итеп куллану өчен аның карары белән дәүләт музеена яисә муниципаль музейга тапшырылырга мөмкин.»;

11) 32 статьяда:

а) 1 өлештә «гражданны яисә оешманы» сүзләрен «гражданны, муниципаль берәмлекне яисә оешманы» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «гражданга яисә оешмага» сүзләрен «гражданга, муниципаль берәмлеккә яисә оешмага» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2020 ел, 10 март
№ 8-ТРЗ